ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.07.2019 п.г.т.Алексеевское № 312

**«Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**хокук бозулар профилактикасы буенча**
**ведомствоара комиссия турында»**
**башкарма комитетның 25 июнь,2018 ел, 165 нче**
**карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Коралның, сугыш кирәк-яраклары һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен булдырмау чаралары турында"гы 15 август, 545 нче карарын гамәлгә ашыру һәм халыкта законсыз саклана торган коралны ирекле рәвештә бушлай алу чараларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрү максатында

**карар бирәм:**

1. "Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы хокук бозулар профилактикасы буенча ведомствоара комиссия турында"гы 25 июнь, 2018 ел карары белән расланган Нигезләмәнең 3 нче бүлеген түбәндәге пунктлар белән тулыландырырга:

"3.6. Татарстан Республикасында һәм аның филиалларында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күп функцияле үзәге" дәүләт бюджет учреждениесеннән килүче документлар нигезендә коралны, аның состав өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, корал патроннарын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны ирекле тапшырган өчен акчалата бүләкләүнең күләмен билгеләп, акча түләүгә ризалык һәм бирүдән баш тарту турында нәтиҗә әзерләү";

«3.7 Коралны, аның состав өлешләрен, сугыш кирәк-яракларын, корал патроннарын, шартлаткыч матдәләрне һәм шартлаткыч җайланмаларны ирекле тапшырган өчен акчалата бүләкләүнең күләмен билгеләп, акча түләүгә ризалык һәм бирүдән баш тарту турында нәтиҗәне Татарстан Республикасы Алексеевск

муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлегенә җибәрергә”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районы рәсми сайтында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.П.Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**